| | |
|---|---|
| БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» 04 2026 ел № 168

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенен 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы чараларын һәрьяклап тәэмин итүне оештыру максатларында Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Балтач муниципаль районының оешма, учреждение (аларның оештыру-хокукый формаларына карамастан) җитәкчеләренә, гамәлдәге законнар нигезендә оешмада гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмә әзерләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Җитәкче А.Ф.Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2026 елның «20» 04
168 номерлы карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмә

1. Әлеге Нигезләмә «Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турында Нигезләмәне раслау хакында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карары, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турында Нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Президентының 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Указы, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының «Муниципаль берәмлекләрдә һәм оешмаларда гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 14 ноябрендәге 687 номерлы боерыгы нигезендә эшләнде һәм гражданнар оборонасын алып баруны һәм алып баруга әзерлекнең оештыруны һәм төп юнәлешләрен, шулай ук Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районында (алга таба – Балтач муниципаль районы) гражданнар оборонасы буенча төп чараларны билгели.

2. Балтач муниципаль районында Гражданнар оборонасы буенча чаралар Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасын алып бару һәм алып баруга әзерлек кысаларында оештырыла.

3. Гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлардан, шулай ук Балтач муниципаль районында гадәттән тыш хәлләр, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда яклауга әзерлек чараларын алдан үтәүдән гыйбарәт һәм гражданнар оборонасы мәсьәләләре буенча төп чараларны күздә тоткан еллык план нигезендә гамәлгә ашырыла. (алга таба - Балтач муниципаль районының төп чаралар планы).

4. Балтач муниципаль районының бер елга төп чаралар планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан эшләнә һәм гражданнар оборонасы бурычларын һәм гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын хәл итәргә махсус вәкаләтле орган белән, Татарстан Республикасы буенча Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла - казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан килештерелә (алга таба – Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе).

Гражданнар оборонасын алып бару һәм алып баруга әзерлек буенча төп чараларны планлаштыру Балтач муниципаль районы территориясендә хәрби

актлары һәм гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәсендә килеп чыгарга мөмкин булган вәзгыятьне һәрьяклап бәяләүне исәпкә алып башкарыла.

5. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек муниципаль берәмлектә гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмә белән билгеләнә һәм Балтач муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда килеп чыга торган куркынычлардан саклау чараларын планлаштырудан гыйбарәт.

Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасын алып бару Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы нигезендә гамәлгә ашырыла һәм Балтач муниципаль районы территориясендә халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп чыкканда килеп туа торган куркынычлардан саклау чараларын үтәүдән гыйбарәт.

6. Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планы сугыш вакытында гражданнар оборонасын әзер хәлгә китерү һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү буенча чараларның күләмен, оештырылуын, тәэмин ителеше тәртибен, ысулларын һәм башкару срокларын билгели.

Тыныч вакытта гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү чараларын үтәү табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча гамәлләр планы нигезендә башкарыла.

6.1. Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәүне тәэмин итү идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балтач районы башкарма комитеты Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы чараларын үтәүне тәэмин итә торган оешмалар исемлеген билгели.

7. Балтач район башкарма комитеты Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында гражданнар оборонасы өлкәсендәге вәкаләтләре нигезендә көчләр, чаралар, Гражданнар оборонасы объектлары, матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чараларның запасларын булдыра һәм аларны үз эченә ала, Гражданнар оборонасы буенча чаралар планлаштыра һәм гамәлгә ашыра.

8. Балтач район башкарма комитеты карары буенча коткару хезмәтләре (медицина, инженер, коммуналь-техник, янгынга каршы, җәмәгать тәртибен саклау, хайваннарны һәм үсемлекләрне яклау, хәбәр итү һәм элемтә, транспорт белән тәэмин итү һәм ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү, юл, энергетика һәм сәүдә, туклану) төзелергә мөмкин, аларны оештыручы органнар һәм коткару хезмәтләре турында нигезләмәләргә

Коткару хезмәте составына Гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү, һәлакәттән коткару формированиеләре гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү һәм хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен билгеләнгән идарә органнары, гражданнар оборонасы көчләре һәм чаралары керә.

Коткару хезмәтләренең төре һәм саны Гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау планнары нигезендә башкарыла торган бурычларның күләмен һәм характерын исәпләү нигезендә билгеләнә.

Балтач муниципаль районының коткару хезмәте турындагы нигезләмә коткару хезмәте җитәкчесе тарафыннан эшләнә, Татарстан Республикасының тиешле коткару хезмәте җитәкчесе белән килештерелә һәм Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан раслана.

Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыруга һәм аларның әзерлеген тәэмин итүгә методик җитәкчелек итү, шулай ук бу өлкәдә контроль Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла - казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгы (алга таба-Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгы) һәм Россия Гражданнар оборонасы министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

9. Эвакуация чараларын планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү өчен Балтач район башкарма комитеты тыныч вакытта алдан ук эвакуация комиссиясе төзи. Эвакуация комиссиясен Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары җитәкли. Эвакуация комиссиясе эшчәнлеге Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе тарафыннан раслана торган эвакуация комиссиясе турындагы Нигезләмә белән регламентлана.

10. Гражданнар оборонасы көчләре тыныч вакытта табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү чараларында катнашу өчен җәлеп ителергә мөмкин.

Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы җитәкчесе Гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетерү өчен тыныч вакытта гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын җәлеп итү турында карарны үзе төзегән гражданнар оборонасы көчләренә карата кабул итә.

11. Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы белән Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе җитәкчелек итә.

Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын оештыру һәм үткәрү өчен шәхсән җаваплы.

12. Балтач муниципаль районында гражданнар оборонасы белән идарә итүне гамәлгә ашыручы орган булып Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә төзелә торган гражданнар оборонасы өлкәсендәге гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү бурычларын хәл итүгә вәкаләтле структур бүлекчә тора.

Балтач район башкарма комитеты Гражданнар оборонасы өлкәсендә гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бурычларны хәл итүгә

Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча вәкаләтле структур бүлекчә җитәкчесе турыдан-туры Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенә буйсына.

13. Балтач муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы буенча чараларны оешкан һәм планлы рәвештә гамәлгә ашыруны тәэмин итү, шул исәптән тыныч һәм сугыш чорында фаразлана торган һәм килеп туган куркынычлар турында халыкка үз вакытында хәбәр итү максатларында гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аны алмашу оештырыла.

Балтач муниципаль районы территориясендә мәгълүмат җыю һәм алмашу «Балтач муниципаль районының гражданнарны яклау идарәсе» муниципаль казна учреждениесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Балтач район башкарма комитеты мәгълүматны Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшыра.

14. Муниципаль дәрәҗәдә гражданнар оборонасы гамәлләре федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары, Россия гадәттән тыш хәлләр министрлыгының норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы җитәкчесенең күрсәтмә документлары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашырыла.

15. Балтач район башкарма комитеты Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү максатларында түбәндәге төп чараларны планлаштыра һәм гамәлгә ашыра:

15.1. Гражданнар оборонасы өлкәсендә халыкны әзерләү буенча:

Гражданнар оборонасы һәм табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә халыкны әзерләүнең бердәм системасы эшчәнлеген норматив-методик тәэмин итүне үстерү;

халыкны Гражданнар оборонасы өлкәсендә укытуны планлаштыру һәм гамәлгә ашыру;

Балтач районында гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәк, гражданнар оборонасы вазыйфаи затларына һәм хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирүнең башка оешмалары, Гражданнар оборонасы буенча укыту-консультация пунктлары булдыру, җиһазландыру һәм эшчәнлеген һәрьяклап тәэмин итү, шулай ук Балтач муниципаль районы муниципаль берәмлекләренең Гражданнар оборонасы курслары эшләвен тәэмин итү;

Гражданнар оборонасы өлкәсендәге оешма хезмәткәрләрен әзерләү өчен укыту матди-техник база булдыру һәм аны эш хәлендә тоту;

Гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалау;

15.2. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында барлыкка килә торган куркынычлар турында халыкка хәбәр итү буенча:

халыкка үзәкләштерелгән хәбәр итү системасын булдыру һәм даими әзерлек халәтендә тоту, аны яңа буын техник чаралар базасында

I һәм II классны хәвефле куркыныч җитештерү объектларын, аеручa радиация һәм атом-төш куркыныгчы производстволарын һәм андагы авария нәтиҗәләренең зарарлы факторлары йогынты ясаган зоналарында бу территорияләрдән читтә яшәүче яисә хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыручы халыкның гомеренә һәм сәламәтлегенә зыян китерергә мөмкин булган объектларны, югары куркынычлы гидротехник корылмаларны эксплуатацияләүче оешмалар тарафыннан локаль хәбәр итү системаларын булдыру һәм аларны әзерлек халәтендә тоту;

кешеләр күпләп була торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм мәгълүмат бирүнең махсуслаштырылган техник чараларын урнаштыру;

бердәм электр элемтәсе челтәре чараларыннан, радио, чыбыклы һәм телевизион тапшырулар челтәреннән һәм чараларыннан, шулай ук мәгълүмат тапшыруның башка техник чараларыннан комплекслы файдалану;

гражданнар оборонасы өлкәсендә мәгълүмат җыю һәм аның белән алмашу;

15.3.Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү буенча:

эвакуацияне планлаштыру, әзерләү һәм уздыруны оештыру;

эвакуацияләнергә тиешле халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне урнаштыру өчен имин районнар әзерләү;

эвакуация органнарын төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук аларның шәхси составын әзерләү;

15.4.Халыкка индивидуаль һәм күмәк яклау чаралары бирү буенча:

гражданнар оборонасының саклану корылмаларын һәм аларның техник системаларын төзү, саклап калу, билгеләнеше буенча файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту һәм техник хезмәт күрсәтү;

Тыныч вакытта, гражданнар оборонасын алып баруга әзерлек халәтенә китергәндә һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасын алып бару барышында, халыкны ышыклау өчен тирәнәйтелгән биналарны һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларын җайлаштыру;

гражданнар оборонасын тыныч вакытта әзерләү һәм ул кертелгәндә, аны сугыш вакытында алып бару барышында гадиләштерелгән эчке җиһазлары һәм иң гади гигиена ышык урыннары булган гражданнар оборонасының тиз төзелә торган саклану корылмаларын төзү;

гражданнар оборонасының саклау корылмаларында, тирәнәйтелгән биналарда һәм җир асты киңлегенең башка корылмаларында халыкны яшерүне тәэмин итү;

индивидуаль яклау чараларын туплау, саклау, яңарту һәм билгеләнеше буенча файдалану;

халыкка индивидуаль яклау чараларын бирүне һәм күмәк яклау чараларын билгеләнгән срокларда бирүне тәэмин итү;

тыныч һәм сугыш чоры куркынычларын, гражданнар оборонасының саклану корылмалары булуны һәм гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау буенча планлаштырыла торган чаралар булуны исәпкә алып, халыкны ышыклау өчен метрополитенны тыныч вакытта җайлаштыру;

маскировкаланырга тиешле объектлар исемлеген билгеләү;

Гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә билгеләнгән тәртиптә кертелгән территорияләрне, шулай ук заманча җимерү чараларын кулланганда ихтимал максатлар булып торучы оешмаларны комплеклы маскировкалауны гамәлгә ашыру планнарын эшләү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмалар тарафыннан яктылык маскировкасы һәм маскировканың башка төрләре буенча чаралар үткәрү өчен кирәкле матди-техник чаралар запасларын билгеләү буенча куллануга даими әзерлек халәтендә булдыру һәм тоту;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән оешмаларның демаскировкалау билгеләрен киметү буенча инженер-техник чаралар үткәрү;

15.6. Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә халык өчен куркыныч килеп чыккан очракта, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару буенча:

гражданнар оборонасының кирәкле көчләрен һәм чараларын, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерүнең бердәм дәүләт системасын булдыру, җиһазландыру һәм әзерләү, шулай ук аларның гамәлләрен планлаштыру;

һәлакәттән коткару эшләрен һәрьяклап тәэмин итү өчен матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын билгеләү буенча файдалануга даими әзерлек халәтендә тоту һәм булдыру;

һәлакәттән коткару эшләрен башкару өчен заманча технологияләр һәм техник чаралар эшләү;

Гражданнар оборонасы көчләренең Россия Федерациясе Кораллы Көчләре, башка гаскәрләр, хәрби формированиеләр һәм органнар, шулай ук сугыш вакытында төзелә торган махсус формированиеләр белән үзара хезмәттәшлеген оештыру;

Гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итү өчен җәлеп ителә торган һәлакәттән коткару штаттан тыш формированиеләренең һәм гражданнар оборонасы буенча чаралар үтәлешен тәэмин итү буенча штаттан тыш формированиеләрнең реестрларын исәпкә алу һәм алып бару;

15.7. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында зыян күргән халыкны беренчел тормыш белән тәэмин итү буенча:

халыкның тормышын тәэмин итүнең төп төрләрен планлаштыру һәм оештыру;

матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасларын булдыру һәм куллануга даими әзерлектә тоту;

халыкны азык-төлек һәм азык-төлек булмаган товарлар белән норма нигезендә тәэмин итү;

халыкка коммуналь-көнкүреш хезмәтләре күрсәтү;

хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә

зыян күрүчеләрне дәвалау учреждениеләренә эвакуацияләү;

тораксыз калган халык санын билгеләү;

сакланып калган торак фондын инвентаризацияләү һәм аның торышын бәяләү, аны зыян күргән халыкны урнаштыру өчен файдалану мөмкинлеген билгеләү, тораксыз калган кешеләрне ял йортларында, пансионатларда һәм башка сәламәтләндерү учреждениеләрендә, вакытлыча торакларда (җыелма йортларда, палаткаларда, землянкаларда h. б.) урнаштыру, шулай ук халыкны сакланып калган торак фонды мәйданына күчерүне гамәлгә ашыру;

халыкка мәгълүмати-психологик ярдәм күрсәтү;

15.8. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә барлыкка килгән янгыннарга каршы көрәш буенча:

янгынга каршы кирәкле көчләр булдыру, аларны матди-техник чаралар белән тәэмин итү һәм гражданнар оборонасы өлкәсендә әзерләү;

сугыш вакытында һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкарылган районнарда янгыннарны сүндерү;

билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы категорияләренә кертелгән объектларда сугыш вакытында янгыннарны сүндерү;

15.9. Радиоактив, химик, биологик яисә башка төрле йогышлануга дучар булган районнарны ачыклау һәм билгеләү буенча:

Балтач муниципаль районы территориясендә радиацияле, химик, биологик хәлне күзәтү һәм контрольдә тоту функцияләрен гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының һәм оешмаларның гамәлдәге махсуслаштырылган учреждениеләрен, бүлекчәләрен һәм хезмәтләрен - гражданнар оборонасын һәм халыкны яклауны күзәтү һәм лаборатор контрольдә тоту челтәрен булдыру һәм әзерлеген тәэмин итү;

радиоактив зарарлануга (пычрануга) дучар булган территорияләрдә радиациядән саклану режимнарын кертү;

радиация, химик, биологик вәзгыятьне, шул исәптән азык-төлекнең һәм әйләнә-тирә мохит объектларының радиоактив, химик һәм биологик матдәләр белән зарарлану (пычрану) дәрәҗәсен мониторинглау ысулларын һәм техник чараларын камилләштерү;

15.10. Халыкны санитар эшкәртү, биналарны һәм корылмаларны зарарсызландыру, техниканы һәм территорияләрне махсус эшкәртү буенча:

дезактивацияләүче, дегазацияләүче һәм дезинфекцияләүче матдәләр һәм эремәләр запасын алдан булдыру;

халыкны санитар эшкәртү һәм техниканы, биналарны һәм территорияләрне зарарсызландыру өчен гражданнар оборонасы көчләрен булдыру, шулай ук аларны гражданнар оборонасы өлкәсендә җиһазландыру һәм әзерләү;

техниканы, биналарны һәм территорияләрне зарарсызландыру, халыкны санитар эшкәртү чараларын үткәрүне оештыру;

15.11. Хәрби конфликтлар вакытында яки шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында зыян күргән районнарда тәртипне торгызу һәм саклау буенча:

җәмәгать тәртибен торгызу һәм саклау, шәһәрләрдә һәм башка торак пунктларда, халыкны эвакуацияләү һәм гражданнар оборонасы көчләрен чыгару маршрутларында юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү;

Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләре тарафыннан мәҗбүри сакланырга тиешле объектларны һәм юридик һәм физик затлар милкәтен саклауны көчәйтү (тиешле шартнамәләр нигезендә), караусыз калган милкәтне саклау буенча чаралар күрү;

15.12. Сугыш вакытында кирәкле коммуналь хезмәтләрнең эшләвен ашыгыч торгызу мәсьәләләре буенча:

коммуналь хезмәтләрнең сугыш чоры шартларында эшләүгә әзерлеген тәэмин итү һәм аларның гамәлләрен планлаштыру;

газ, энергия һәм су белән тәэмин итүнең зарарланган системаларын ремонтлау өчен җиһазлар запасын һәм запас частьләр булдыру;

суны чистарту, төчеләндерү һәм транспортировкалау өчен мобиль чаралар резервын булдыру һәм әзерләү;

сууткәргеч станцияләрендә реагентларның, реактивларның, консервантларның һәм дезинфекцияләү чараларының кирәкле запасларын булдыру;

резервуарлар һәм сыешлыклар запасын, җыю-сүтеп алу торбаүткәргечләрен, мобиль резерв һәм автоном энергия чыганакларын, башка кирәкле җиһазлар һәм техник чаралар булдыру;

15.13. Сугыш вакытында мәетләрне ашыгыч күмү буенча:

Күмү урыннарын алдан билгеләү;

мәетләрне ашыгыч күмү чараларын тәэмин итү өчен гражданнар оборонасы көчләрен һәм чараларын булдыру, әзерләү һәм әзерлектә тоту, шул исәптән махсуслаштырылган ритуаль оешмалар базасында;

мәетләрне танып белү, исәпкә алу һәм күмү буенча чараларны законнарда билгеләнгән кагыйдәләрне үтәп оештыру һәм үткәрү;

санитар-эпидемиологик күзәтчелекне оештыру;

15.14. Хәрби конфликтлар вакытында яисә шушы конфликтлар нәтиҗәсендә, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр вакытында халыкның исән калуы өчен кирәкле оешмалар эшчәнлегенең тотрыклылыгын тәэмин итү буенча:

тыныч һәм сугыш вакытында икътисад объектлары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру мәсьәләләре буенча комиссияләр төзү һәм аларның эшен оештыру;

торак пунктларны, икътисад һәм инфраструктура объектларын, шулай ук җитештерү чараларын төзелеш нормалары һәм гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын гамәлгә ашыру кагыйдәләре таләпләре нигезендә рациональ урнаштыру;

газ, энергия һәм су белән тәэмин итү системалары һәм чыганаклары эшчәнлегенең ышанычлылыгын арттыруга юнәлдерелгән чаралар эшләү һәм үткәрү;

тыныч һәм сугыш вакытында гражданнар оборонасының инженер-техник чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру;

сугыш вакытында эшен дәвам итә торган икътисад объектларында һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләрне планлаштыру, әзерләү һәм уздыру;

житештерү процессын саклап калу һәм (яисә) торгызу өчен кирәкле матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралар запасын алдан булдыру;

документациянең иминият фондын булдыру;

заманча зарарлау чаралары тәэсирендә житештерү фондларын яклауның нәтиҗәлелеген арттыру;

15.15. Гражданнар оборонасы көчләренең һәм чараларының даими әзерлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча:

Гражданнар оборонасы көчләрен булдыру һәм заманча техник чаралар белән жиһазландыру;

Гражданнар оборонасы көчләрен әзерләү, гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнекмәләр үткәрү;

Гражданнар оборонасы көчләренең гамәлләрен планлаштыру;

һәлакәттән коткару һәм башка кичектергесез эшләр башкару өчен югары нәтиҗәле технологияләр эшләү;

Гражданнар оборонасы көчләре һәм чараларының үзара хезмәттәшлек итү һәм җәлеп итү тәртибен билгеләү, шулай ук аларның гамәлләрен һәрьяклап тәэмин итү.

16. Балтач муниципаль районының Гражданнар оборонасы чараларын финанслау гамәлдәге кануннар нигезендә башкарыла.